СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.09.2018 ел с. Сарманово № 138

**Сарман муниципаль районы территориясендә аерым категория гражданнарга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру турында**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Сарман муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы Л. М. Гыйльметдинованың "Сарман муниципаль районы территориясендә аерым категория гражданнарга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру турында" мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль районның норматив-хокукый актларында каралган социаль ярдәм чараларын алу хокукына ия гражданнар категориясен тулысынча үтәү максатларында, муниципаль район Советы карар кабул итте:

1. Мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Районның җирле үзидарә органнары депутатларына мәгълүматны үз округларындагы сайлаучылар белән эшләүдә файдаланырга тәкъдим итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына:

- гражданнарга социаль ярдәм чаралары төрләре һәм аларны рәсмиләштерү тәртибен аңлату буенча эшне дәвам итәргә;

- ялгыз, аз керемле өлкән яшьтәге гражданнарга, шулай ук мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү чараларын алу һәм тиешле документлар рәсмиләштерү өчен гариза бирүгә ярдәм итәргә;

- гражданнар җыеннары, хезмәт коллективлары җыелышлары көн тәртибенә халыкны социаль яклау хезмәтләренең район территориясендә халыкка социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында мәгълүмат кертү.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципальн район
Советы рәисе Ф.М. Хөснуллин